ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

13.11.2019 с. Набережные Моркваши 5

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Покровка авылы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Покровка авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын үткәрүне 2019 елның 8 декабрендә 09 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2. Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлеге Покровка авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын үткәрүне 2019 елның 8 декабрендә 11 сәгать 00 минутта билгеләргә.
3. Халыкның бүленеш исемлеген территориаль билге буенча тормышка ашырырга.

1 этап: Покровка авылы, Центральная, Лесная урамнары халкы

2 этап: Покровка авылы, Фурцевская урамы халкы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

**- Покровка авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау**

**- Покровка авылында су белән тәэмин итү системасын ремонтлау**

« ӘЙЕ» «ЮК»

5. Халык җыеннары үткәрергә:

1 этап: Покровка авылы, Центральная урамы, № 19 йорт янында

2 этап: Покровка авылы, Центральная урамы, № 216 йорт янында

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районы**
**Яр Буе Морквашы авыл җирлеге**
**Башлыгы** **И.Х.Гаязов**